**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 4 май** **№ 40**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлегенең генераль планын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2021 елның 22 гыйнварындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru/).
3. "Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең генераль планы турында" 2013 елның 19 декабрендәге 80 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**